**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**14.03.2018** **№ 581**

**2018 елда Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны оештыру турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, СанПиН 2.4.5.2409-08 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 сентябрендәге 664 номерлы «2017 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләме турында» карарын үтәү йөзеннән, шулай ук балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, 2018 елда Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны тәэмин итү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен кайнар туклану оештырырга.

Укучыларның туклану чыгымнарын финанслауга гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәгеләрне җибәрергә:

- гомуми белем бирү оешмаларында көнгә бер укучыга - 7 сум 10 тиен исәпләп республика бюджетының айлык акчалата түләүләрен;
- гомуми белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш акчалары;
- ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ирекле кертемнәре;
- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган күпбалалы гаиләләрдән укучылар өчен гомуми белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш акчалары исәбеннән иртәнге кайнар ашлар оештырырга.

2. «Биектау 3 нче урта мәктәбе» МББУ (Шеваловский А.В.) һәм «Г.Баруди исемендәге 4 нче Биектау урта мәктәбе» МББУнә (Гаязов Р.Р.) «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» муниципаль унитар предприятиесе белән берлектә укучыларны тукландыруны оештыру эшен дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

3. Укучыларны гамәлдәге законнарга туры китереп кайнар туклandыруны оештыру өчен җаваплылыкны гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә йөкләргә.

4. Татарстан Республикасында Роспотребнадзор идарәсенең Арча, Биектау муниципаль районнарында (Арча ТБ) территориаль бүлегенә (Салкова Э.В.) район гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны туклandыруны оештыру өчен китерелә торган азык-төлек продуктлары сыйфатына даими контроль ясарга, укучыларның туклануын мөстәкыйль оештыручы учреждениеләрдә гамәлдәге законнар (шул исәптән лаборатор контроль) нигезендә туклануны оештыруның җитештерү контролен тәэмин итәргә.

5. ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына район бюджетыннан ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ сметасы буенча билгеләнгән нормативларга туры китереп укучыларны туклandыруга максатчан чараларны үз вакытында финанслауны тәэмин итәргә.

6. «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә (Әхмәтҗанов Н.К.), ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Кадыйров Н. К.) укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны, исәпкә алуны тәэмин итәргә, мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашларының ассортиментын һәм рационын баету буенча эшне көчәйтергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкчесе урынбасары - «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Н. К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ф.Хөснетдинов